КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 июнь г.Казань № 481

Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» илкүләм проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру чаралары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» илкүләм проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында 2019 – 2021 елларда халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру турында» 2018 елның 27 декабрендәге 1695 номерлы карарын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» милли проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында мәшгульлек хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә

ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслашуга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» милли проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслашуга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү өлешендә Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча федераль хезмәт белән багланышларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма орган итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 10 июнь, 481 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» милли проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында мәшгульлек хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслашуга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» милли проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында мәшгульлек хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслашуга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансферт) рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибен билгели.

2. Федераль бюджеттан башка бюджетара трансферт Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган шәхси счетка керә.

3. Башка бюджетара трансфертны тоту әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм башка бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат алынганнан соң җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) башка бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерә.

5. Министрлык Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан агымдагы финанс елына башка бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләме турында мәгълүмат алганнан соң җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына бүтән бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә кадәр җиткерә (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) әлеге учреждениеләр эшчәнлеген оештыруга карата Министрлык тарафыннан билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең нәтиҗәлелеген арттыру чараларын гамәлгә ашыра.

6. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән акчалар халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны финанслауга җибәрелә, әлеге учреждениеләр эшчәнлеген оештыруга бердәм таләпләрне гамәлгә кертү өлешендә, шул исәптән:

а) бердәм таләпләр кертүне гамәлгә ашыручы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре хезмәткәрләрен укыту;

б) бердәм таләпләр кертүне гамәлгә ашыручы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре биналарын һәм бүлмәләрен агымдагы ремонтлау;

в) бердәм таләпләр кертүне гамәлгә ашыручы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре хезмәткәрләре эш урыннарын уңайлы шартлар дәрәҗәсен тәэмин итүне үз эченә җиһазлау;

г) Татарстан Республикасы территориясендә бердәм таләпләрне гамәлгә кертүне һәм таратуны оештыру һәм методик яктан тәэмин итү, шул исәптән халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте эшчәнлегенә җәлеп ителгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын эшләүне, гамәлгә кертүне һәм эшчәнлеген оештыру-методик яктан тәэмин итүне кертеп, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре тарафыннан мәгълүмат саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә якланган элемтә каналларының эшен булдыру һәм тәэмин итү (аларны агымдагы карап тотудан тыш).

7. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре аларга билгеләнгәнбюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә һәм әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән акчалар алар исәбенә кергән саен дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында закон таләпләре нигезендә дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзелгән оешмалар счетларына акча күчерүне гамәлгә ашыралар.

8. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре хисап чорыннан соң килүче айның 11 көненнән дә соңга калмыйча Министрлыкка финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап, Министрлык раслаган формалар буенча башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләренең әһәмиятенә ирешү турында хисап тапшыралар.

Министрлыкка тапшырылган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.

9. Министрлык, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре 2019 елның 11 февралендәге 150-17-2019-089 номерлы Россия Федерациясе субъекты бюджетына максатчан билгеләнешкә ия булган башка бюджетара трансферт бирү турында килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек (нәтиҗәләр) күрсәткечләренә ирешү өчен (алга таба – Килешү) җаваплылык тота.

10. Министрлык Килешүгә кушымталар нигезендә формалар буенча Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча федераль хезмәткә билгеләнгән вакытта хисаплар бирә.

Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча федераль хезмәткә тапшырылган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык Министрлыкка йөкләнә.

11. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына кергән башка бюджетара

трансферттан максатсыз файдалану бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

12. Хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган башка бюджетара трансферт калдыклары Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

13. Әгәр дә башка бюджетара трансфертлар бирү елының 31 декабренә әлеге Тәртипнең 9 пунктында каралган йөкләмәләрне бозуга юл куелган һәм башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 25 гыйнварына кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән булса, Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджетка кире кайтарылырга тиешле финанс чаралары күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» илкүләм проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында 2019 – 2021 елларда халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру турында» 2018 елның 27 декабрендәге 1695 номерлы карары белән расланган «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» илкүләм проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында 2019 – 2021 елларда халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә исәпләнә.

14. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын тикшерүдә тоту Министрлык һәм Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---